| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

| | | |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**03.04.2025** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 925** |

Яшь гаиләләргә торак сатып алуга бирелә торган социаль түләүләр күләмен исәпләү өчен 2025 елның икенче кварталына Зеленодольск муниципаль районы буенча гомуми торак мәйданының бер квадрат метры хакы нормативын билгеләү турында

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 6 июлендәге «2020 - 2026 елларга «Зеленодольск муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасын раслау турында» 1219 номерлы карары белән расланган «2020-2026 елларга Зеленодольск муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасын гамәлгә ашыру кысаларында, Яшь гаиләләргә торак сатып алуга социаль түләүләр бирү кагыйдәләренең 10 пункты, «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Яшь гаиләләргә торак сатып алуга бирелә торган социаль түләүләр күләмен исәпләү өчен 2025 елның икенче кварталына Зеленодольск муниципаль районы буенча гомуми торак мәйданының бер квадрат метр хакы нормативын 89 232 (сиксән тугыз мең ике йөз утыз ике) сум күләмендә билгеләргә.
2. Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми (http://pravo. tatarstan.ru) порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат (http://zelenodolsk. tatarstan.ru) сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О.А. Матвеевага йөкләргә.

Җитәкче З.Ф.Хәбибуллин